ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03 март 2021 ел № 1441

Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре
исемлеген раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру максатында

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) муниципаль хезмәтләр исемлеген 1 нче кушымтада каралганча;

2) дәүләт хезмәтләре исемлеген 2 нче кушымтада каралганча.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карары;

2) «Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 24 июнендәге 3237 номерлы Башкарма комитет карары;

3) 2016 елның 15 декабрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 13 декабрендәге 6675 номерлы Башкарма комитет карары;

4) 2017 елның 10 февралендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 8 февралендәге 588 номерлы Башкарма комитет карары;

5) 2017 елның 5 маенда «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 3 маендагы 2747 номерлы карары;

6) 2017 елның 3 октябрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 28 сентябрендәге 5805 номерлы карары;

7) 2018 елның 20 июлендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru һәм 2018 елның 25 июлендә «Челнинские известия» газетасының 53 нче санында бастырып чыгарылган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 18 июлендәге 4000 номерлы Башкарма комитет карары;

8) 2018 елның 1 августында «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru һәм 2018 елның 8 августында «Челнинские известия» газетасының 57 нче санында бастырып чыгарылган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 июлендәге 4226 номерлы Башкарма комитет карары;

9) 2018 елның 8 августында «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru һәм 2018 елның 15 августында «Челнинские известия» газетасының 59 нчы санында бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре исемлегенә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 2 августындагы 4343 номерлы Башкарма комитет карары;

10) 2018 елның 26 ноябрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru һәм 2018 елның 5 декабрендә «Челнинские известия» газетасының 88 нче санында бастырып чыгарылган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 22 ноябрендәге 6940 номерлы Башкарма комитет карары;

11) 2019 елның 7 мартында «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru һәм 2019 елның 20 мартында «Челнинские известия» газетасының 19 нчы санында бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 5 мартындагы 1144 номерлы Башкарма комитет карары;

12) 2019 елның 24 маенда «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru һәм 2019 елның 29 маенда «Челнинские известия» газетасының 37 нче санында бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 23 маендагы 2663 номерлы Башкарма комитет карары;

13) 2019 елның 18 сентябрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru һәм 2019 елның 20 сентябрендә «Челнинские известия» газетасының 69 нчы санында бастырып чыгарылган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре исемлегенә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 16 сентябрендәге 4705 номерлы Башкарма комитет карары;

14) 2019 елның 12 ноябрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru һәм 2019 елның 15 ноябрендә «Челнинские известия» газетасының 84 нче санында бастырып чыгарылган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 8 ноябрендәге 5755 номерлы Башкарма комитет карары;

15) 2019 елның 5 декабрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru һәм 2019 елның 6 декабрендә «Челнинские известия» газетасының 90 нчы санында бастырып чыгарылган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре исемлегенә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 3 декабрендәге 6264 номерлы Башкарма комитет карары;

16) 2020 елның 17 февралендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru һәм 2020 елның 14 февралендә «Челнинские известия» газетасының 11 нче санында бастырып чыгарылган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 7 февралендәге 545 номерлы Башкарма комитет карары;

17) 2020 елның 4 мартында «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru һәм 2020 елның 4 мартында «Челнинские известия» газетасының 16 нчы санында бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 28 февралендәге 980 номерлы Башкарма комитет карары;

18) 2020 елның 15 маенда «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru һәм 2020 елның 15 маенда «Челнинские известия» газетасының 35 нче санында бастырып чыгарылган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 8 маендагы 2152 номерлы Башкарма комитет карары;

19) 2020 елның 29 маенда «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru һәм 2020 елның 27 маенда «Челнинские известия» газетасының 38 нче санында бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 22 маендагы 2407 номерлы Башкарма комитет карары;

20) 2020 елның 24 июлендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru һәм 2020 елның 22 июлендә «Челнинские известия» газетасының 53 нче санында бастырып чыгарылган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 20 июлендәге 3470 номерлы Башкарма комитет карары.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага һәм Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 3 мартындагы
1441 номерлы карарына
1 нче кушымта

Муниципаль хезмәтләр исемлеге

1. «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы буенча исәпкә кую һәм торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү.
2. Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую.
3. Торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую.
4. Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны һәм аларга тиңләштерелгән затларны исәпкә кую һәм Дәүләт торак сертификаты бирү.
5. торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм күчеп китәргә мәҗбүр булганнарга торак сатып алу өчен субсидия бирүгә Дәүләт торак сертификаты бирү.
6. Күпфатирлы йорттагы бүлмәне үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү.
7. Торак урыннарны гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү.
8. Социаль наем шартнамәсе буенча гражданга муниципаль милектәге торак урынны бирү.
9. Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урыннарны алмаштыру буенча документлар рәсмиләштерү.
10. Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану.
11. Торак урынны торак булмаган урын һәм торак булмаган урынны торак урын итеп күчерү.
12. Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү.
13. Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү.
14. Кадастр исәбенә кую максатында муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан җир участокларының чикләрен килештерү.
15. Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү.
16. Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү.
17. Җир участогының шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү.
18. Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару.
19. Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү.
20. Агачларны һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кисүгә яки утыртуга рөхсәт бирү.
21. Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү.
22. Җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан файдаланучыларга мәгълүмат бирү.
23. Муниципаль милектәге җир участогын даими (сроксыз) файдалануга бирү.
24. Территориянең кадастр планында җир участогының яки җир участокларының урнашу схемасын раслау.

25. Муниципаль милектәге җир участогын милеккә бушлай бирү.

26. Муниципаль милектәге җир участогын җир участогында урнашкан биналар, корылмалар милекчеләренә милеккә яки арендага бирү.

27. Җир участогыннан даими (сроксыз) файдалану хокукын яки җир участогын гомерлек мирас итеп биләү хокукын туктату турында карар кабул итү.

28. Муниципаль милектәге җир участогын түләүсез файдалануга бирү.

29. Муниципаль милектәге җир участогын индивидуаль торак төзелеше өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү.

30. Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә сату.

31. Муниципаль мөлкәт реестрыннан өземтә бирү.

32. Җир участогын арендалау шартнамәсенә үзгәрешләр кертү.

33. Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү.

34. Архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив документлары күчермәләрен бирү.

35. Муниципаль архивның уку залында эшләү өчен файдаланучыга архив документларын бирү.

36. Юридик затларга архивлар эшендә һәм эш башкаруда документлар оештыру буенча методик һәм практик ярдәм күрсәтү.

37. Архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация бирү.

38. Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир участогын милеккә бушлай бирү (тапшыру).

39. Муниципаль казна мөлкәтен арендага бирү.

40. Чит җир участогыннан чикле файдалану хокукы (сервитут) бирү.

41. Элек приватизацияләнгән торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү.

42. Җир участогының шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү.

43. Коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте әгъзасы булып торган гражданга җир участогын бушлай бирү.

44. Хезмәт урыныннан бирелә торган торак урынны наемга алу шартнамәсе буенча гражданнарга торак урыннар бирү.

45. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасы мәгълүматларын бирү.

46. Җир участогын арендалау шартнамәсен өзү.

47. Җир участогын субарендага тапшыруга рөхсәт бирү.

48. Муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәсен өзү.

49. Муниципаль мөлкәтне сатулар үткәрмичә түләүсез файдалануга тапшыру.

50. Муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану шартнамәсе төзү хокукына сатулар нәтиҗәләре буенча шундый шартнамә төзү.

51. Муниципаль преференцияләр бирү.

52. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү.

53. Территориаль иҗтимагый үзидарә рәисенә таныклык бирү.

54. Җир участогы бирүне алдан килештерү.

55. Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә арендага бирү.

56. Дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир участокларын һәм шәхси милектәге җир участокларын яңадан бүлү турында килешү төзү.

57. Муниципаль милектәге җир участогын бакчачылык алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү.

58. Муниципаль милектәге җир участогын аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда арендага бирү.

59. Җир участогын аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда сату юлы белән муниципаль милектәге җир участогын милеккә бирү.

60. Тышкы мәгълүмат чарасын урнаштыру проектын (паспорт) килештерү.

61. Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны урнаштыру өчен җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә, дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрне яки җир участокларын файдалануга рөхсәт бирү.

62. Яр Чаллы шәһәре өстендә авиация эшләре, парашюттан сикерү, һава судноларының демонстрацион очышлары, пилотсыз һава судноларының очышлары (максималь очыш массасы 0,25 килограммнан ким булган пилотсыз һава судноларының очышларыннан тыш), бәйләп куела торган аэростатларны күтәрү, шулай ук алар хакында белешмәләр аэронавигация мәгълүматлары документларында күрсәтелмәгән Яр Чаллы шәһәре чикләрендә урнашкан мәйданчыкларга төшү (очып китү) өчен рөхсәт бирү.

63. Планлаштырылган төзелеш яки реконструкцияләү турындагы белдерү кәгазендә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе (туры килмәве) һәм җир участогында индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру рөхсәт ителү (рөхсәт ителмәү) турында белдерү кәгазе җибәрү.

64. Төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында белдерү кәгазе җибәрү.

65. Җир участогының рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү.

66. Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу.

67. Чит җир участогыннан чикле файдалану хокукы (җәмәгать сервитуты) бирү.

68. Капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү.

69. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урынын (мәйданчыгын) булдыруны килештерү.

70. Каты коммуналь калдыкларны җыю урыны (мәйданчыгы) турындагы мәгълүматларны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урыннары (мәйданчыклары) реестрына кертү.

71. Биналарның фасадларына өстәмә җиһаз урнаштыру буенча архитектура йөкләмәсе әзерләү.

72. Рекультивация проектын капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә проект документлары составында әзерләү очракларыннан һәм федераль законнар белән билгеләнгәнчә, җирләрне рекультивацияләү проекты расланганчы ул дәүләт экспертизасы үтәргә тиешле очраклардан тыш, җирләрне рекультивацияләү проектын килештерү.

73. Җирләрне консервацияләү проектын килештерү.

74. Инженерлык челтәрләре һәм коммуникацияләре трассаларының схемасын килештерү.

75. Капиталь төзелеш объектын сүтүне планлаштыру турында белдерү кәгазен һәм документларны шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында урнаштыру һәм бу хакта региональ дәүләт төзелеш күзәтчелеге органына хәбәр итү.

76. Капиталь төзелеш объектын сүтү тәмамлану турында белдерү кәгазен шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында урнаштыру һәм бу хакта региональ дәүләт төзелеш күзәтчелеге органына хәбәр итү.

77. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан стационар булмаган сәүдә объектының архитектура-шәһәр төзелеше күренеше проектын килештерү.

78. Аукцион үткәрмичә, муниципаль милектәге җир участокларында, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир участокларында стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру хокукына шартнамә төзү.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2021 елның 3 мартындагы
1441 номерлы карарына
2 нче кушымта

Дәүләт хезмәтләре исемлеге

1. Стационар хезмәт күрсәтү өчен, опекага алынган затларны стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтә торган социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына җибәрү турында карарлар бирү.
2. Суд тәртибендә хокукка сәләтсез яки хокукка сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булган затка опека яки попечительлек билгеләү һәм опекун яки попечитель билгеләү.
3. Опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсе төзүгә рөхсәт бирү.
4. Опекунга балигъ булган хокукка сәләтсез зат мәнфәгатьләрендә торакны приватизацияләүгә рөхсәт бирү.
5. Опекунга опекага алынган затка караган торакны наемга бирүгә рөхсәт бирү.
6. Опекага алынган затның мөлкәте белән килешүләрне гамәлгә ашыруга рөхсәт бирү.
7. Опекунга, яшәү урынын алыштыру сәбәпле, опекага алынган затны яшәү урыны буенча теркәү исәбеннән төшерүгә рөхсәт бирү.
8. Опекунга яки попечительгә опекага алынган затның мирас хокукына керергә рөхсәт бирү.
9. Опекунга яки попечительгә опекага алынган затның саклык счетыннан файдаланырга рөхсәт бирү.
10. Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмалардагы балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү.
11. Балигъ булмаган зат(лар) исеменнән өстенлекле сатып алу хокукыннан баш тартуга алдан рөхсәт бирү.
12. Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка (кызлыкка) алучылар булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка (кызлыкка) алучыларга кандидат буларак исәпкә кую.
13. Балигъ булмаганнарның күчемле милкен тартып алу буенча килешүләрне гамәлгә ашыруга алдан рөхсәт бирү.
14. Үндүрт яшькә җитмәгән баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү.
15. Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга опека (попечительлек) билгеләү (түләүле һәм түләүсез шартларда) яки опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү.
16. Эмансипация (балигъ булмаган затны тулысынча хокукка сәләтле дип белдерү) турында карар кабул итү.
17. Балигъ булмаган затка караган күчемсез милекне тартып алу буенча килешүләрне гамәлгә ашыруга алдан рөхсәт бирү.
18. Балигъ булмаганнар катнашында кредит акчаларыннан файдаланып торак сатып алуга һәм аны залогка (ипотекага) тапшыруга алдан рөхсәт бирү.
19. Законлы вәкилгә балигъ булмаган затның акчалата кертемен алуга рөхсәт бирү.
20. Үз вазыйфаларын түләүле башкаручы опекунга яки попечительгә, тәрбиягә бала алган ата-аналарга баланы (балаларны) караган өчен акча билгеләү һәм түләү, шулай ук

опекуннарга яки попечительләргә, тәрбиягә бала алган ата-аналарга бирелергә тиешле акчаларны түләү.

21. Дәүләт милкенә караган архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация бирү.

22. Муниципаль архивның уку залында эшләү өчен файдаланучыга дәүләт милкенә караган һәм муниципаль архивта саклана торган архив документларын бирү.

23. Дәүләт милкенә караган һәм муниципаль архивта саклана торган архив фондлары буенча архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив документлары күчермәләрен бирү.

24. Төзүченең һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1.1 һәм 2 өлешләрендә, 3.2, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү.

25. Аерылышуны дәүләт теркәвенә алу.

26. Язылышуны дәүләт теркәвенә алу.

27. Гражданнар хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында кабат таныклыклар бирү.

28. Тууны дәүләт теркәвенә алу.

29. Үлүне дәүләт теркәвенә алу.

30. Уллыкка (кызлыкка) алуны дәүләт теркәвенә алу.

31. Ата булуны билгеләүне дәүләт теркәвенә алу.

32. Исем алмаштыруны дәүләт теркәвенә алу.

33. Гражданнар хәле актлары язуларына төзәтмәләр һәм үзгәрешләр кертү.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Н.И. Галиева